СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 8-26 от «27» декабря 2023 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2021 елның 12 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында» № 9-9 карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар, Татарстан Республикасы «Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Мамадыш муниципаль районы Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2021 елның 12 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында» № 9-9 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2021 елның 12 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында» № 9-9 карары белән расланган «Муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлегеен» яңа редакциядә түбәндәгечә бәян итәргә:

«1. Автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм торак пункт чикләрендә юл хуҗалыгында һәм (яисә) бер үк җирле әһәмияттәге юлда юл хуҗалыгында муниципаль контроль объектында утыз календарь көн дәвамында ике һәм аннан да күбрәк юл-транспорт һәлакәте.

2. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы тарафыннан ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша бирелгән мәгълүматлар

000149

нигезендә, контрольдә тотылган зат йөртүчеләре тарафыннан бер календарь ел дәвамында даими пассажирлар йөртү маршрутында автомобиль транспорты, шәһәр, җир өсте, электр транспорты белән юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозу очракларының биш процентка һәм аннан да күбрәккә артуы.

3. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы тарафыннан ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша бирелгән мәгълүматлар нигезендә, бер календарь ел эчендә юл инфраструктурасы объектында юл-транспорт һәлакәтләре санының алдагы календарь ел белән чагыштырганда ике һәм аннан да күбрәк тапкыр артуы.

4. Контрольдә тотылучы зат билгән яисә файдаланган юл участогында узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда юл-транспорт һәлакәтләренең ( 3 хокук бозудан да ким булмаганда) календарь аена кимендә биш процентка артуы.

5. Хисап елы дәвамында юлның бер участогында, йә юл һәм урамнар киселешендә, канәгатьләнерлек булмаган юл шартларына бәйле рәвештә, кешеләр зыян күргән яисә яраланган бер төрдәге юл-транспорт һәлакәте килеп чыгу фактларын ачыклау»;

2. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, “Интернет” мәгълүмати-коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo. tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Район башлыгы урынбасары Р.Р. Сәмигуллинга йөкләргә.

Район Башлыгы,
муниципаль район
Советы рәисе — А.П. Иванов